ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында” 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда “эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы” сүзләрен “эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын бозган өчен җаваплылык билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы” сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 статья. **Норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау**

1. Норматив хокукый актлар проектларына әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла торган җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиеш, моңа түбәндәгеләр керми:

а) региональ салымнарны, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

б) бюджетка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектлары.

2. Норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм Татарстан Республикасы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

3. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актларга, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә экспертиза ясалырга тиеш.";

3) 5 статьяда:

а) исемдә "Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә "Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы" сүзләрен "Әлеге Закон нигезендә җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиешле" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 26 марты
№ 14-ТРЗ